ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 5 Әбсәләм ав. 18 апрель 2024 ел

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2005 елның 21 июлендәге «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында»гы 97-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы Карары проектын (алга таба - карар проекты) 1 нче кушымта нигезендә хупларга һәм ачык тыңлауларга чыгарырга.

2. Карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. Карар проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү көне һәм вакыты 2024 елның 29 маенда мәскәү вакыты белән 18 сәгать 00 минутта;

3.2. Карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру урыны – Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы;

3.3. Карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү формасы – җыелыш.

3.4. Карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес –423957, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм авылы, Яшьләр урам, 2 йорт, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы.

4. Түбәндәгеләрне расларга:

4.1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составы (алга таба-оештыру комитеты) (2 нче кушымта);

4.2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карары проектына тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алу тәртибе (3 нче кушымта).

5. Оештыру комитетына түбәндәгеләрне йөкләргә:

5.1. 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның

28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм әлеге карар нигезендә, ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрүне;

5.2. Ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советына ачык тыңлаулар беркетмәсен, ачык тыңлаулар тәкъдимнәрен, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарны мотивацияле нигезләүне, ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗә ясауны, шулай ук (үзгәрешләр кертү очрагында) карарның эшләп бетерелгән проектын тапшырырга;

5.3. Карар проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклыгы № ФС77-60244 от 17.12.2014) челтәр басмасында, http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында урнаштыру, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт,җирлекнең Башкарма комитет бинасы; Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык урамы, 3 санлы йорт яны адреслары буенча, шулай ук федераль дәүләт мәгълүмат системасында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы»нда кире элемтә платформасының җәмәгать тавыш бирү подсистемасында (ПОС). халык тыңлаулары уздырылганнан соң 5 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5.4. 2024 елның 19 апреленә кадәр әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклыгы № ФС77-60244 от 17.12.2014) челтәр басмасында, http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында урнаштыру, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт,җирлекнең Башкарма комитет бинасы; Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык урамы, 3 санлы йорт яны адреслары буенча, шулай ук федераль дәүләт мәгълүмат системасында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы»нда кире элемтә платформасының җәмәгать тавыш бирү подсистемасында (ПОС) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 18 апрелендәге 5 санлы карарына 1 кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ _________ Әбсәләм ав. ________ 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Конституциясе, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2005 елның 21 июлендәге «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында»гы 97-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 29 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар протоколын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 29 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 ноябрендәге 29 санлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе юстиция Министрлыгы Идарәсенең 2023 елның 6 декабрендәге RU165433022023001 санлы дәүләт теркәү саны белән теркәлгән (алга таба – Устав) Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Уставның 7 маддәсенең 1 пунктының 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру»;

1.2. Уставның 38 маддәсенең 1 пунктының 27 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

1.3. Уставның 55 маддәсенең 1 пунктындагы 10 пунктчасының 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

1.4. Уставның 61 маддәсенең 3 пункты түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктчасы белән тулыландырылырга:

«13) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкетадагы билгеле булган мәгълүматларның үзгәрүе турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш) (анкетада булганнары)»;

1.5. Уставның 80 маддәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хокукый актларны игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе» турындагы 80 маддә

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, нигез салучы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) тулы текстны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә (https://pravo.tatarstan.ru; ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык no ФС77-60244 17.12.2013 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) яки «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») периодик вакытлы басмасында бирелгән (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык no ФС 77-47613 07.12.2011 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән басмада бастырып чыгару;

2) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру;

3) Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт,җирлекнең Башкарма комитет бинасы; Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык урамы, 3 санлы йорт яны адреслары буенча торак пунктлар территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт, админитсратив бина адресы буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 10 көн эчендә игълан ителә.

5. Җирлек советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

6. Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

7. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә, хокукый авыл җирлеге башлыгы акты».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны http://jutaza.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Порталы составында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында дәүләт теркәвеннән соң, Интернет челтәре басмасында Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәгълүмат рәгълүматы рәсми порталының http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча (ММЧны теркәү турындагы таныклык 17.12.2014 № ФС77-60244), Интернет челтәре басмасында http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф веб-адреслары буенча Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар (ММЧ ның 2018 елның 05 мартындагы 77-72471 номерлы теркәү турындагы таныклык) адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 44 маддәсенең 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В.Кубашева

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 18 апрелендәге 5 санлы карарына 2 кушымта

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| № п/п | Ф.И.А. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1 | Кубашева Гөлназ Валериевна | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы |
| 2 | Габидуллина Рәзинә Рәис кызы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе |
| 3 | Шәмсуллина Гөлнара Шат кызы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы депутаты |
| 4 | Хәмидуллин Илгизәр Зәйнулла улы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы депутаты |
| 5 | Хәлитов Альберт Марат улы | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы депутаты |

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советының 2024 елның 18 апрелендәге 5 санлы карарына 3 кушымта

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карар проектына тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы карары проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр (алга таба - карар проекты), Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге халкы тарафыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгына http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклыгы № ФС77-60244 от 17.12.2014) челтәр басмасында, http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында урнаштыру, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт,җирлекнең Башкарма комитет бинасы; Әбсәләм тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык урамы, 3 санлы йорт яны адреслары буенча урнашкан торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмати стендларда басылып чыккан көннән алып, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында җәмәгать тавыш бирү подсистемасында язма рәвештә кире элемтә платформасын урнаштыру юлы белән 423957, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт адресы буенча шәхсән таблица формасында җибәрелә:

| № п/п | Бүлек, бүлекчә | Карар проекты тексты | Проект тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А., адресы, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр юнәлеше җәмәгать тыңлаулары уздырылганчы 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге халкының чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризаларны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгына карар проекты http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (ЭЛ массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турында таныклыгы № ФС77-60244 от 17.12.2014) челтәр басмасында, http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында урнаштыру Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт,җирлекнең Башкарма комитет бинасы; Әбсәләм

тимер юл разъезды бистәсе, Тынычлык урамы, 3 санлы йорт яны адреслары буенча урнашкан торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмати стендларда басылып чыккан көннән алып, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында җәмәгать тавыш бирү подсистемасында язма рәвештә кире элемтә платформасын урнаштыру юлы белән 423957, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авыл җирлеге, Әбсәләм авылы, Яшьләр урамы, 2 йорт адресы буенча шәхсән китерә алалар.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Гаризалар җибәрү җәмәгать тыңлаулары уздырылганчы 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге халкының тәкъдимнәре, искәртмәләре һәм гаризалары Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карау өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгында тапшырыла.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең барлык кызыксынучы кешеләре дә ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукысыз катнаша ала.

5. Катнашучыларны теркәү җәмәгать тыңлаулары башланганчы 30 минут алдан башлана.

6. Ачык тыңлауларда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы рәислек итә.

7. Җәмәгать тыңлаулары рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышу мәсьәләсенең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

8. Беркетмәне рәсмиләштерү, килгән тәкъдимнәрне, рекомендацияләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкче һәм сәркатипнең ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

9. Төп доклад белән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы чыгыш ясый.

10. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар чыгыш ясау хокукы белән гариза бирү вакытына бәйле рәвештә үз тәкъдимнәрен чиратлап дәлилләү өчен чакырыла.

11. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

12. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

13. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар җәмәгать тыңлаулары барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Җәмәгать тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау җәмәгать тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Катнашучылар җәмәгать тыңлауларын үткәрү тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче җәмәгать тыңлаулары сәркатибе җитәкчесенә җәмәгать тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, киңәшләрне төгәлләү өчен сүз бирә ала.

17. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның барлык тәкъдимнәре һәм искәртмәләре сәркатипкә язма рәвештә бирелә һәм җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә кушыла. Ачык тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче кул куя һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

18. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре буенча нәтиҗә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

19. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре буенча нәтиҗә ачыкланырга тиеш.

20. Җәмәгать тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.